РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

21.10.2022 | № 1058-п

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 18 сентябрендәге 1191-п номерлы карары белән расланган Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендәге муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Граждан оборонасы, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү системасын камилләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 14 августындагы 569 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасында бюджетара мөнәсәбәтләр формалаштырганда исәпкә алына торган, Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, су объектларында кешеләрнең янгын куркынычсызлыгын һәм иминлеген тәэмин итү өлкәсендә муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләүгә Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетлары чыгымнары күләмен билгеләү методикасының 2 кушымтасына үзгәреш кертү турында" 2020 елның 16 октябрендәге 935 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

**1.** Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының «Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өлкәсендә муниципаль берәмлек хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 18 сентябрендәге 1191-п номерлы карары белән расланган, Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су

объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендәге муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы Нигезләмәгә (Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 29.01.2018 №78-п, 16.05.2019 №495-п, 13.11.2020 №1556-п карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1.1.** Нигезләмәнең 1 нче таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"

| № т/б | Хезмәткәрләр вазыйфалары | Вазыйфаи оклад күләме, сум |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Учреждение җитәкчесе | 19862,0 |
| 2 | Оператив дежур торучы | 15279,0 |

»;

**1.2.** Нигезләмәнең 5 пунктындагы 3 абзацын төшереп калдырырга;

**1.3.** Нигезләмәнең 6 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

**1.4.** Нигезләмәнең 8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләр белән эшләгән өчен айлык өстәмәләр - елына 0,3 вазыйфаи оклад күләмендә.

Дәүләт серен тәшкил иткән белешмәләр белән эшләгән өчен күрсәтелгән айлык өстәмә түләү законнарда билгеләнгән тәртиптә рөхсәт язуын рәсмиләштерү шарты белән даими нигездә дәүләт серен белгән хезмәткәрләргә түләнә.»;

**2.** Әлеге карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

**3.** Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

Саба муниципаль районы
Башкарма комитеты Җитәкчесе М.Р. Ишниязов